**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2025 елның 31 гыйнварындагы 198 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Авиатөзелеш районында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 12464 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары 16:00:0000:1054, 16:00:0000:1050, 16:00:0000:1549, 16:00:0000:68996;
- хокуклар чикләнә торган кадастр кварталлары – 16:16:212208, 16:16:216403, 16:50:320124;
- урнашкан урыны: Казан шәһәре, Авиатөзелеш районы;
- билгеләү максаты: Адреслары: ТР, Казан шәһәре, «КАПО №11» коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте, «КАПО №14» коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте, «Связь» коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте, «Промстройматериаллар» коммерцияле булмаган бакчачылык ширкәте булган җир кишәрлеге чигенә кадәр газүткәргечнең тармаклануы» җирле әһәмияттәге газ белән тәэмин итүнең линия объектларын урнаштыру;
- билгеләү вакыты: 10 ел;

1.2. гариза бирүче: «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

1.3. билгеләүгә нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясының 1 пункты, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, РФ Хөкүмәтенең 2000 елның 20 ноябрендәге 878 номерлы «Газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрен раслау турында»гы карары, Казан шәһәр Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре округының Генераль планы, РФ Президенты В.В.Путин йөкләмәсе нигезендә, гражданнарның акчаларын җәлеп итмичә, газлаштырылган пунктларда җир кишәрлекләре чикләренә кадәр газ кертү программасы.

2. Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сервитутны гамәлгә ашыру белән бәйле рәвештә сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясындагы 2, 3, 4, 5, 7 һәм 8 пунктлары нигезендә гамәлгә кертелә дип билгеләргә.

4. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

5. Әлеге карарны, 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

7. «Газпром трансгаз Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

7.1. әлеге карарның 1.1 пунктында күрсәтелгән 16:00:000000:1054, 16:00:000000:1050, 16:00:000000:1549 кадастр номерлы җир кишәрлекләре хуҗалары белән ачык сервитут башкару турында килешү төзергә;


7.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яисә агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яки Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларында каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 31 гыйнварындагы
198 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең Авиатөзелеш районында**
**ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштаб 1:10000
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |

| | |
|---|---|
| | гамәлдәге җир кишәрлекләренең чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар (гамәлдәге) |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:16:212208, 16:16:216403, 16:50:320124 | кадастр кварталы |
| 16:00:000000:1054, 16:00:000000:1050, 16:00:000000:1549, 16:00:000000:68996 | Үзенә карата хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |